ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
Арча муниципаль районының
Арча шәһәр муниципаль берәмлеге
Арча шәһәр Советы
422000, Арча шәһәре,Совет мәйданы, 27
тел. 3-15-25, 3-16-25

РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
Муниципальное образование город Арск
Арского муниципального района
Совет города Арск
422000, г. Арск, Площадь Советская , 27
тел. 3-15-25, 3-16-25

**Арча шәһәр Советы**

**КАРАРЫ**

**« 30 » декабрь 2020 ел** **№ 23**

**«Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы “Арча «Арча шәһәре» муниципаль берәмлегендә гавами тыңлаулар (җәмәгать фикер алышулары) оештыру һәм уздыру тәртибе турындагы Нигезләмәне раслау хакында» 2018 елның 13 декабрендәге 99 номерлы Арча шәһәр Советы карарына (2018 елнын 20 декабрендэге үзгәрешләр белэн) үзгәрешләр кертү турында**

Прокуратура күрсәтмәсе нигезендә, Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Арча муниципаль берэмлеге халкының муниципаль хокукый актлар проектлары турында фикер алышуда катнашу хокукын гамәлгә ашыру максатыннан һәм «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 28 статьясына, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 20 статьясына, Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы “Арча шәһәре” муниципаль берэмлеге” Уставына таянып, Арча шәһәр Советы карар бирде:

1. “Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы «Арча шәһәре» муниципаль берәмлегендә гавами тыңлаулар (җәмәгать фикер алышулары) оештыру һәм үткәрү тәртибе турындагы Нигезләмәне раслау хакында” 2018 елның 13 сентябрендәге 99 номерлы карары белән расланган "Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы «Арча шәһәре» муниципаль берәмлегендә гавами тыңлаулар (җәмәгать фикер алышулары) оештыру һәм үткәрү тәртибе турындагы Нигезләмәгә (2018 елнын 20 декабрендэге №113 узгэрешлэр белэн) түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

**1) 4 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:**

**«4 статья. Гавами тыңлаулар инициаторлары**

Гавами тыңлаулар халык, Арча шәһәр Советы (алга таба - Совет), авыл җирлеге башлыгы (алга таба - башлык), үз вәкаләтләрен Регламент нигезендә контракт буенча гамәлгә ашыручы Арча шәһәр башкарма комитеты җитәкчесе (алга таба - БК җитәкчесе) инициативасы белән үткәрелә.»;

2) 5 статьяның 1 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1. Халык яки Совет инициативасы буенча үткәрелә торган гавами тыңлаулар Совет карары белән билгеләнә.

Җирлек башлыгы яки үз вәкаләтләрен контракт нигезендә гамәлгә ашыручы Арча шәһәр башкарма комитеты җитәкчесе инициативасы буенча үткәрелә торган гавами тыңлаулар җирлек башлыгы тарафыннан билгеләнә.

Гавами тыңлаулар Россия Федерациясе законнары буенча җирле үзидарә органнары вәкаләтләренә кертелгән мәсьәләләр буенча үткәрелә.»;

3) 6 статьяның 1.1 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1.1. Гавами тыңлауларның нәтиҗәләре, кабул ителгән карарларны дәлилле нигезләп, массакүләм мәгълүмат чараларында, Арча муниципаль районы рәсми сайтында һәм (яисә) башка мәгълүмат системаларында һәм мәгълүмат стендларында бастырып чыгарыла (халыкка җиткерелә).

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга һәм Арча муниципаль районы рәсми сайтында (http://arsk.tatarstan.ru) урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

3. Карар рәсми игълан ителгән көненнән үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны «Арча шәһәре» муниципаль берәмлеге башлыгы урынбасарына йоклэргэ.

«Арча шәһәре» муниципаль
берәмлеге башлыгы,
Арча шәһәр Советы рэисе — И.Г.Нуриев

МУНИЦИПАЛЬНОЕ ОБРАЗОВАНИЕ "ГОРОД АРСК" АРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АРЧА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ АРЧА ШӘҺӘРЕ МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
ОГРН 1121690009220
«Совет города Арск»
ИНН1609012686